# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# ӨТӘШКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

2023 елның 6 марты № 104

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Өтәшкә авыл җирлеге» Советының 2013 елның 14 ноябрендәге 130 номерлы карары белән расланган (Өтәшкә авыл җирлеге Советының 09.08.2014 елның №164, 15.12.2018 елның №147, 12.11.2019 елның №184, 02.06.2021 елның № 37 карарлары белән расланган үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Бюджет процессын камилләштерү өлешендә Россия Федерациясе Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү сәбәпле, Өтәшкә авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Өтәшкә авыл җирлеге Советының 2013 елның 14 ноябрендәге 130 номерлы карары белән расланган (Өтәшкә авыл җирлеге Советының 09.08.2014 елның №164, 15.12.2018 елның №147, 12.11.2019 елның №184, 02.06.2021 елның № 37 карарлары белән расланган үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында түбәндәге үзгәрешләр:

1.1. 6 статьяны түбәндәге эчтәлекле унберенче абзац белән тулыландырырга:

«гражданнарның бюджет процессында катнашуы;»;

алдагы редакциянең унберенче - ундүртенче абзацлары чын редакциянең уникенче - унбишенче абзацлары булып санала.

1.2. 9 статьяның 5 пунктының икенче өлешен түбәндәге эчтәлектәге өченче абзац белән тулыландырырга:

«Федераль казначылык органында, Татарстан Республикасы финанс органында, муниципаль берәмлек финанс органында, Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фонды белән идарә итү органында (Россия

Федерациясе Үзәк банкы учреждениесендә яки кредит оешмасында) шәхси счет (хисап) ачылмаганда бурычлы казна учреждениесеннән акча, шул исәптән суд чыгымнарын түләтү турында;»

алдагы редакциянең өченче - дүртенче абзацлары чын редакциянең дүртенче - бишенче абзацлары булып санала.

1.3. 9 статьяның 9 пунктындагы өченче абзацына сүзләр өстәргә:

«(бюджетның бердәм счетында калган акчалар белән идарә итү операцияләреннән, бердәм салым түләүгә бәйле операцияләрдән, Евразия икътисадый берлеге хокукы һәм Россия Федерациясе законнарында мәҗбүри түләүләргә карата каралган алдан түләү белән бәйле операцияләрдән, Евразия икътисадый берлеге хокукы һәм таможня җайга салуы турында Россия Федерациясе законнарында каралган акчалата залог белән бәйле операцияләрдән тыш);»;

1.4. 9 статьяның 10 пунктындагы икенче абзацына сүзләр өстәргә: (бюджетның бердәм счетында калган акчалар белән идарә итү операцияләреннән, бердәм салым түләүгә бәйле операцияләрдән, Евразия икътисадый берлеге хокукы һәм Россия Федерациясе законнарында мәҗбүри түләүләргә карата каралган алдан түләү белән бәйле операцияләрдән, Евразия икътисадый берлеге хокукы һәм таможня җайга салуы турында Россия Федерациясе законнарында каралган акчалата залог белән бәйле операцияләрдән тыш);

1.5. 19 статьяның 2 пунктындагы 4 пунктчасында «муниципаль гарантияләргә» сүзләрен «, муниципаль гарантияләрдән килеп чыга торган» сүзләре белән алмаштырырга;

1.6. 20 статьяның 1 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бурыч йөкләмәләре турында мәгълүмат (муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләрдән тыш) күрсәтелгән органнар тарафыннан муниципаль бурыч кенәгәсенә тиешле йөкләмә барлыкка килгән вакыттан алып биш эш көненнән дә артмаган срокта кертелә.».

«2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталының Интернет челтәрендә (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Өтәшкә авылы, Нагорная урамы, 99а йорт (җирлек администрациясе бинасы), Өтәшкә авылы, Үзәк урамы, 40а йорты (мәдәният йорты бинасы) адреслары буенча урнашкан информацион стендларында урнаштырырга.

**Өтәшкә авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе** **А. А. Клопов**